# Тел язмышы – милләт язмышы





Герой - шагыйрь Муса Җәлилнең тууына 115 ел. Менә быел да шагыйрьнең туган көне уңаеннан техникум китапханәсендә “Шагыйрь эзләреннән” исемле кичә үткәрелде.

Әйе, һәр халыкның үлемсез шагыйрьләре, телдән-телгә күчә торган легендар батырлары була. Муса Җәлил - шундый каһарманнарның, язучыларның берсе. Аның тормышы фашистларның кулында фаҗига белән тәмамланса да, шигъри язмышы бәхетле. Ул - үлем аша үлемсезлеккә атлаган бөек шәхес. Еллар үткән саен Муса Җәлилнең кеше күңеленә үтеп керү осталыгы, рухи көче, тәэсирлеге, нәфислеге арта гына бара.

Каһарман шагыйрьгә багышланган “Җәлил мәңгегә безнең күңелләрдә” һәм “Гомерем минем моңлы бер җыр иде” дигән күргәзмәләр белән таныштык. Кичә бик күңелле узды.

*130 нчы төркем студенты Фәхретдинова Динара*

### “Нәүрүз гүзәле - 2021”






Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы уңаеннан Буа ветеринария техникумында “Нәүрүз гүзәле - 2021” дигән музыкаль кичә уздырылды. Техникумның иң уңган, булган, матур, сылу биш кызы осталыкта һәм уңганлыкта, җитезлеклектә, тапкырлыкта көч сынашты. Бәйге башлануын игълан иткәч, кызлар төз итеп атлап, бер-бер артлы зал уртасына уздылар. Кызларның йөзләреннән нур бөркелә, шул ук вакытта дулкынлану мизгелләре дә чагыла.

Дулкынлану һәм бер мәлгә читенсенеп, югалып калу мизгелләре булгаласа да, жюриның сынаулы карашлары төбәлсә дә, кызлар һич кенә дә бирешмәделәр, ә киресенчә, тагын да яхшырак булсын дигәндәй, бар сәләтләрен эшкә җиктеләр, сер бирмәделәр.

Шакирова Азалия һәр номерны бөтен нечкәлекләренә кадәр туры китереп үтәп, "Нәүрүз гүзәле" исеменә лаек булды. Кызларыбызга киләчәктә зурдан-зур уңышлар теләп калабыз!

*Татар теле һәм әдәбияты укытучысы Гомәрова Г.М.*

### «Festival of English language» фестивале






31 март көнне техникум актлар залында «Festival of English language» дип исемләнгән инглиз теле укытучылары Шакурова М.Ф., Фомина А.П., Хазиев С.Р. тарафыннан әзерләнгән тантана уздырылды. Фестивальнең эчтәлеге һәм формасы планлаштырылган максатларга һәм куелган бурычларга тулысынча туры килә: чара зур танып-белү кыйммәтенә ия, инглиз теленә һәм өйрәнелә торган тел иленә карата кызыксыну тәрбияләү, ягъни укучыларның фәнгә мотивациясен арттыру; студентларның күпкырлы һәм гармонияле үсеш алган шәхесен формалаштыруга ярдәм итте. Җыр, сәнгатьле уку, бию, эрудиция, конферанс номинацияләрендә укучылар көч сынаштылар. Жюри әгъзалары Буа драма театрының әдәби-драма өлеше җитәкчесе Халитова Г.И., инглиз теле укытучысы Идиатуллина Г.С., экология, биология укытучысы Антонова Т.А. барлык катнашучыларның чыгышларын югары бәяләделәр һәм истәлекле бүләкләр, дипломнар тапшырдылар.

*Инглиз теле укытучысы Шакурова М.Ф*

**Наш адрес:**
422430 г.Буинск
ул. Северная Коммуна д.41
тел.:8(84374) 3-12-94

**Редакторы:**
Каримова А.Ф.
Латыпова Г.Ф.
Гумерова Г.М.

**Компьютерная верстка и дизайн:**
Мелихов Г.

# Ветеринарный Вестник



*«Буа ветеринария техникумы»* *Апрель 2021 ел*
*Махсус чыгарылыш*

## 2021нче ел - Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы



Туган тел – бай рухи хәзинә, тутыкмас мәдәни мирас. Ул халыкның милли мәдәниятен чагылдырып кына калмый, аны саклый һәм үстерә дә. Ата-бабаларыбызның телен хөрмәт итеп һәм өйрәнеп, шул телдә аралашып без кабатланмас этник тел атмосферасын тудырабыз, борынгы бабаларыбыз тәҗрибәсен өйрәнәбез, аларның иң яхшы әхлакый традицияләрен дәвам итәбез, гасырлар буе тупланган социаль нормаларны үзләштерәбез.

Бүгенге көндә үсеп килүче яшь буынны халкыбызның традицияләре үрнәгендә тәрбияләү – мөһим бурычларның берсе. Балага милли гореф-гадәтләр, милли традицияләр никадәр иртәрәк бирелсә, ул шәхес буларак шулкадәр көчле, телен, илен, милләтен сөя белүче буларак үсәчәк.

Үз телен, милләтен, мәдәниятен белеп, аңа хөрмәт белән карый белүче генә башка милләт вәкилләрен, аларның гореф-гадәтләрен ихтирам итә белә. Техникумда төрле милләт балалары белем ала. Без, студентларга белем бирү белән беррәттән, милли тәрбия бирүне гамәлгә ашырабыз, милли үзаңны үстерү юнәлешендә максатчан эш алып барабыз. Баланы үз милләтенең лаеклы вәкиле һәм камил шәхес буларак тәрбияләү өчен, аңа туган телен өйрәнү генә аз. Аның өчен тел милли гореф-гадәтләрне аңга сеңдерү, саклау, киләчәк буыннарга тапшыру чарасына әверелергә тиеш.

Милли тәрбиянең нигезе булып укучыларга туган телне өйрәтү; әдәбиятны, әдәбият аша милли мәдәниятне өйрәтү; гореф-гадәтләргә, тарихи үткәннәргә карата кызыксыну уяту, рухи мирасны өйрәнү, белү, саклау; сыйныфтан тыш тәрбия чаралары ярдәмендә балаларда үз милләтенә хас уңай сыйфатлар тәрбияләү; милли мохит тудыру; ата-аналар һәм гаилә белән берлектә уртак максатка юнәлтелгән бердәм тәрбия эше алып бару тора.

Кадерле дуслар! 26 нчы апрельдә, бөек шагыйребез – татар классик шигърияте нигез салучы Габдулла Тукайның туган көнендә, республикабызда ел саен Туган тел көне билгеләп үтелә. Республикабызда Президентыбыз Р.Н.Миңнеханов игълан иткән Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елында Туган тел көне – һәркайсыбыз өчен һәрвакытта да тынычлык, дуслык һәм татулык бәйрәме булсын! Сезгә чын күңелдән исәнлек-саулык һәм бәхет телим.

*Техникум директоры Гиниятуллин И.М.*





# Бер күрешү – үзе бер гомер



Районыбыз талантлы кешеләргә бай. Алар арасында инде шактый гына тәҗрибә туплаганнар, яңарак кына каләм тибрәтә башлаучылары да бар.

Язучыларының чыгарган китаплары белән, газета-журналлар, интернет челтәрләре аша даими танышып торабыз, әмма якыннан аралашу ул инде бөтенләй башка нәрсә.

"Бер күрешү –үзе бер гомер" дип аталган әдәби – музыкаль кичә районыбызда танылган язучы, шагыйрә-мөгаллимә Гөлнур Айзат иҗатын техникум студентлары белән киң планда таныштыру максатыннан үткәрелде.

Гөлнур Айзат –РФ ның мәгариф отличнигы, Татарстанның атказанган укытучысы, Татарстан Республикасының язучылар берлеге әгъзасы, популяр җырлар авторы.

Гөлнур Айзат 1960 нчы елның 19 нчы февралендә гүзәл Апас районы Иске Энәле авылында туган. Үзе турында шагыйрә менәниләр сөйли:

Минем әнием Рәфыйка, әтием Хәлил – шигъри җанлы, моңсөяр кешеләр. 3 яшемдә сәхнәдә беренче тапкыр җырлаганымны, 10 яшемдә тәүге шигыремне язганымны яхшы хәтерлим. Шуннан соң шигырьләр язу минем көндәлек яраткан эшемә әйләнде. Аларның күбесе Апастагы "Йолдыз", республикабызның "Яшь ленинчы" (хәзерге "Сабантуй"), "Татарстан яшьләре", "Мәгърифәт", "Азат хатын" ("Сөембикә") кебек басмаларында дөнья күрделәр.

- Миннән еш кына: "Хикәя - повесть сюжетларын кайдан аласыз?", - дип сорыйлар. Тормыштан, кеше язмышларыннан. Буш урында әсәр тудырып булмый. Шулай да иң зур илһам чыганагым – улым Идеал, кызым Назлыгөл, ирем Азат, - ди якташыбыз.

Гөлнур Хәлиловна студентларны әле генә "табадан төшкән" шигырьләре , җырлары белән дә таныштырды. Техникум белән бәйле хатирәләрен яңарты:

- Минем әтием Гиниятуллин Халирахман Гиниятулла улы Буа веттехникумында 1954-1957 нче елларда белем алган. Ул комсомол секретаре, бик актив студент булган. Апас районы Иске Әнәле авылыннан коры чакта велосипедта, карлы, янгырлы чакта җәяү йөргән. Техникум аны Свердловск өлкәсенә эшкә җибәргән. Техникум бик ныклы белем бирде, русчаны урысның үзен сатарлык беләм, кызым, - дип көлдерә иде. Шаян, җор телле иде әтием. Әти шәп ветеринар, зоотехник иде, җырга оста, гитарада уйный иде, шигырь, мәкаләләр яза иде.

Техникум укытучылары, студентлар Гөлнур Айзат шигырьләрен, җырларын өйрәнеп кенә калмыйча, якташыбыз иҗаты буенча эзләнү эшләре дә яздылар.

Кичәдә студентлар: Рөстәм Салахетдинов "Минем бабай", Әнисә Хакимова "Күңел", Нариман Җамалетдинов "Сиңа гына" исемле шигырьләрен яттан сөйләделәр. 1 нче номерлы сәнгать мәктәбе укытучысы Мусина Камилла башкаруында "Үз илемдә", 403 нче төркем студенты Айзилә Фәйзрахманова башкаруында "Кичектең", шул ук төркем егете Рәсим Хәйруллин башкаруында "Дуслар белән рәхәт" җырларына Гөлнур апа үзе дә кушылып җырлады, яңа җырларын яңгыратты.

Техникум мөгаллимнәре һәм китапханәче эшләгән күргәзмә, презентацияне югары бәяләп, Гөлнур Айзат рәхмәтен әйтеп, китапханәгә китапларын бүләк итте.

Кичә әдәби-музыкаль рухта узды. Гөлнур апага олы рәхмәтебезне белдереп, киләчәктә иҗади уңышлар, безне яңадан-яңа китаплар белән сөендерүен теләп калабыз! Әлеге очрашу, гомумән, матур, истә калырлык мизгелләргә бай булды.









# Сәнгать аша телгә мәхәббәт тәрбияләү

## Укучыларыбыз "Җырлыйк әле" тапшыруында





Буа ветеринария техникумы студентлары шушы көннәрдә ТНВ каналында "Җырлыйк әле" тапшыруында кунакта булып кайттылар.

Хәйруллин Рәсим республикабызда танылган иң уңган, булган Буа районы Кишер Аксуы авылы егете. Рәсимебез шул мохит гореф-гадәтләренә нигезләнеп тәрбияләнгән авыл җанлы егет. Аның тавышыннан сихри моңнар чагыла. Халкыбызның телен саклау максатында уздырылган барлык бәйгеләрдә актив катнаша.

Низамов Фаил да бик тырыш, ярдәмчел егет. Җырга, моңга гашыйк. Матур итеп баянда уйный, көрәш белән шөгыльләнә. Фаил техникумда күп еллардан бирле эшләүче "Яшьлек" театр труппасының артисты да. Труппа техникумда гына түгел, районыбыз авылларында да үзенең тамашалары белән авыл халкын матур чыгышлары белән шатландырып тора.

Айзилә Фәйзрахманова - Буа районының Күл Черкен авылы кызы. Ул да җырга, моңга гашыйк, вокаль ансамблендә дә чыгыш ясый. Айзилә шулай ук техникумыбызның "Яшьлек" театр труппасының төп актрисасы да. Ул әлеге уку елында Рәсәй күләмендә үткәрелгән Абилимпикс чемпионатында катнашып, бухгалтерлык һөнәре буенча 2 нче урынга лаек булды.

Әлеге студентлар үзләренең моңлы тавышлары белән халкыбызның онытылып бара торган җырларын җырлап, күңелләрне дәртләндереп, ягымлы тавышлары белән безнең күңелләребезне эреттеләр. Тапшыруны 24 нче апрель көнне зәңгәр экраннардан карарга мөмкин.







## "Театр – яктылыкка, нурга илтә"

Соңгы елларда тормышыбызда, яшәешебездә бара торган үзгәрешләрнең берсе - туган халкыбызның милли мәдәниятенә, рухи дөньясына игътибар итү. Шуны искә алып, без дә техникумда халкыбызның матур сәнгате - театр белән балаларны таныштыруны, шул матурлыкны тудырырга омтылыш уятуны төп бурычыбыз итеп куябыз. Безнең уку йортында эшләп килүче "Яшьлек" театр түгәрәге студентлары инде ничәнче ел рәттән районыбыз авылларында Бөтенроссия "Кар десанты" акциясе кысаларында спектакльләрен тәкъдим итәләр.

Узган ел Данил Салиховның "Хиромантлар" комедиясен Низамов Фаил, Асадуллина Илнара, Хәйруллин Рәсим, Вафина Айгөл, Рәхимов Тимур, Фәйзрахманова Айзилә сәхнәләштереп, үз рольләрен югары дәрәҗәдә ачтылар һәм әсәр идеясен тамашачыларга җиткерә алдылар. Театрны тамаша кылган авыл халкы үз чиратында, студентларга рәхмәт белдерделәр һәм уңышлар теләделәр.

Бу елны исә, Айгөл Әхмәтгалиеваның "Ачкыч кайда" комедиясен районыбыз авылларында һәм техникум сәхнәсендә Фәйзрахманова Айзилә, Исхакова Адилә, Хәйруллин Рәсим, Рахманова Венера, Мифтахутдинов Даут тамашачыга тәкъдим иттеләр. Залдан алкышлар тынып тормады, тамашачылар спектакльне бер сулышта карады. Артистларыбыз, әсәрнең кызык, моңсу, хисле һәм шулай ук тирән мәгънә яткан эчтәлеген, тулаем, нәкъ тамашачының күңеленә барып ирешерлек итеп ачып салдылар. Саф хисләрне, ихласлык, матур мөнәсәбәтләрне саклап яши белүче гаиләдән үрнәк алырга булуын күрсәттеләр.

Спектакльдәге рольләрне башкаручылар – зур тәҗрибәле артистлардан һич кенә дә ким түгел икән. Афәрин!., димичә нәрсә әйтәсең?!